# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Арбузов Баран авыл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 12 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Арбузов Баран авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау
-кыш һәм җәйге чорда юлларны карап тоту(чабу, кардан чистарту);
-тракторны карап тоту.
- төзекләндерү (штакетник һәм чыгым материаллары сатып алу);
- плотинаны төзекләндерү өчен материал сатып алу (буа өчен торба);
-бер урынлы бер контейнер мәйданчыгын ясау өчен материал сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 120кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 62кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 62 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлегендәге Арбузов Баран авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2024 елда Алексеевск муниципаль районының « Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Арбузов Баран авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы

гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

-авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау
-кыш һәм җәйге чорда юлларны карап тоту(чабу, кардан чистарту);
-тракторны карап тоту.
- төзекләндерү (штакетник һәм чыгым материаллары сатып алу);
- плотинаны төзекләндерү өчен материал сатып алу (буа өчен торба);
-бер урынлы бер контейнер мәйданчыгын ясау өчен материал сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең Арбузов Баран авыл торак пунктындагы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Алексеевск муниципаль районы
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин